| | | |
|---|---|---|
| **УКАЗ**<br>РАИСА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>РӘИСЕ<br>**УКАЗЫ** |

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының хисап елында эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү өчен ирешелгән күрсәткечләр дәрәҗәсе һәм өчъеллык чорга аларның планлаштырылучы дәрәҗәләре турында Татарстан Республикасы Президенты докладын һәм Татарстан Республикасы шәһәр округларының һәм муниципаль районнарының җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген мониторинглау йомгаклары хакында Татарстан Республикасы җыелма докладын әзерләү тәртибе турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының хисап елында эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү өчен ирешелгән күрсәткечләр дәрәҗәсе һәм өчъеллык чорга аларның планлаштырылучы дәрәҗәләре турында Татарстан Республикасы Президенты докладын һәм Татарстан Республикасы шәһәр округларының һәм муниципаль районнарының җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген мониторинглау йомгаклары хакында Татарстан Республикасы җыелма докладын әзерләү тәртибе турында» 2009 елның 26 мартындагы ПУ-177 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 29 декабрендәге ПУ-1137 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы шәһәр округлары һәм муниципаль районнары җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген мониторинглау йомгаклары турында Татарстан Республикасы җыелма докладын әзерләү тәртибе хакында»;

б) преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Президентының «Муниципаль, шәһәр округларының һәм муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2008 елның 28 апрелендәге 607 номерлы Указын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 17 декабрендәге 1317 номерлы боерыгын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы шәһәр округларының һәм муниципаль районнарының җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген мониторинглау йомгаклары турында Татарстан Республикасы җыелма докладын әзерләүне тәэмин итү максатларында **карар бирәм:**»;

в) 1 пунктның икенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

г) 3 пунктта:

икенче абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимияте органнары» сүзләренә, «күрсәтелгән докладларга» сүзләрен «күрсәтелгән җыелма докладка» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 елның 11 сентябрендәге 1313-р номерлы боерыгы нигезендә расланган» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 17 декабрендәге 1317 номерлы боерыгы нигезендә расланган» сүзләренә алмаштырырга;

д) 1 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга;

е) 2 нче кушымтада:

1 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының» сүзләрен «республика башкарма хакимияте органнарының» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимияте органнары» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктның дүртенче абзацында «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктта «Татарстан Республикасы Социаль-икътисадый мониторинг комитеты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

9 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының» сүзләрен «республика башкарма хакимияте органнарының» сүзләренә алмаштырырга;

12 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2023 ел, 11 май
№ 289